| | |
|---|---|
| **Глава Новоишлинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Башлыгы** |

422475, Республика Татарстан с.Новые Ишли ул.Советская, д.24 тел/факс 88-4375- 30-6-25

==========================================================

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15 сентябрь 2023 ел** **№6**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Яңа Ишле авыл җирлеге җирле
үзидарә органнары муниципаль
хезмәткәренең коррупциягә каршы
тәртибе стандартына үзгәреш кертү турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгының 21.10.2017 ел №9 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы тәртибе стандартына (редакциясендә, 06.06.2018 ел №11; 15.10.2018 ел № 17) түбәндәге үзгәреш кертергә::

3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (тормыш иптәшенең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган мәгълүмат бирү яки дөрес булмаган мәгълүматлар муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

2.Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мухаметзянов